Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы
карары

12 февраль, 2021 ел № 48

«Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авылы, «Волга» М-7 автомобиль юлы буйлап 846+500 км (сулда) адресы буенча урнашкан АГНКСның төп технологик җиһазларын газ белән тәэмин итү өчен» линияле объекты территориясен планлаштыру проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә, 2021 елның 2 февралендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм «Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авылы, «Волга» М-7 автомобиль юлы буйлап 846+500 км (сулда) адресы буенча урнашкан АГНКСның төп технологик җиһазларын газ белән тәэмин итү өчен» линияле объекты территориясен планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Колай авылы, «Волга» М-7 автомобиль юлы буйлап 846+500 км (сулда) адресы буенча урнашкан АГНКСның төп технологик җиһазларын газ белән тәэмин итү өчен» линияле объекты территориясен планлаштыру проектын электрон чыганакта кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов